УДК 821.512.145

***А.Ф. Ганиева***

# ТАТАР СОВЕТ ПРОЗАСЫ: ТӨП ҮСЕШ ЭТАПЛАРЫ ҺӘМ ТЕНДЕНЦИЯЛӘРЕ

В данной работе исследуется советский этап развития татарской литературы как целостный исторический отрезок. Объективная оценка исторического наследия, в особенности переосмысление советской литературы, представляет собой одну из актуальных задач современности. Целью исследования является определение ключевых направлений развития татарской прозы в советскую эпоху. Автор, рассматривая литературный процесс в неразрывной связи с историческими катаклизмами, пережитыми страной, выделяет три ключевых этапа в эволюции татарской советской прозы: 1917–1940, 1941–1955 и 1960–1980-е годы. Исследование ведется в контексте трансформации оппозиции «мы-они», проявившейся в тематических новациях и возрождении художественных традиций национальной литературы.

В заключении утверждается, что, несмотря на значительное идеологическое влияние, характерное для советского времени, татарская проза смогла сохранить свою гуманистическую направленность и национальную самобытность.

**Ключевые слова**: татарская литература, проза, соцреализм, роман, повесть, рассказ, главный герой

This article examines the Soviet period in the development of Tatar literature as a holistic historical period. An objective assessment of the historical legacy, particularly a reinterpretation of Soviet literature, is one of the pressing challenges of our time. The aim of the study is to identify key areas of development in Tatar prose during the Soviet era. The author, examining the literary process inextricably linked to the historical upheavals experienced by the country, identifies three key stages in the evolution of Tatar Soviet prose: 1917–1940, 1941–1955, and 1960–1980. The study is conducted within the context of the transformation of the “us-they” opposition, manifested in thematic innovations and the revival of artistic traditions in national literature.

The conclusion asserts that, despite the significant ideological influence characteristic of the Soviet era, Tatar prose managed to preserve its humanistic focus and national identity.

**Keywords:** Tatar literature, prose, socialist realism, novel, story, short story, protagonist

*(Дәвамы. Башы журналның 2025 елгы 4 нче санында)*

## Милли-мәдәни традицияләр яңару чоры (1960–1985)

1960–1985 еллар татар әдәбияты – совет чорының югары үсешкә ирешкән иң бай дәвере. Илдәге фәнни-икътисади үсеш, демократиянең арта баруы әдәбиятта тематик киңлеккә, жанрларның төр-

леләнүенә, милли мәнфәгатьләрне яклаучы язучыларның кыюлана төшүенә китерә.

Сугыш чорында сизелә башлаган яңарыш 1950 еллар уртасыннан үсеш ала. Моңа Сталинның вафаты, илдә җепшеклек чоры башлану этәргеч бирә. Илдә барган иҗтимагый-сәяси үзгәрешләр язучыларга иркенрәк сулыш алырга мөмкинлек тудыра. Шәхес культы фаш ителү, бик күп талантлы татар әдипләренең исеме реабилитацияләнү – инкыйлабка кадәрге әсәрләрнең халыкка кайтуы әдәби барышны үстереп, җанландырып җибәрә. «Шуларның сәнгати югарылыгын өлге итеп алырга мөмкинлекләр, әдәбиятта XX йөз башында калыплашкан традицияләрне дәвам итәргә шартлар туа. Шуңа күрә дә 1960 еллар татар әдәбиятының яңарышы милли традицияләргә әйләнеп кайту, күпмедер күләмдә XX йөз башында күтәрелеш кичереп, өзелеп калган модернизм эзләнүләрен дәвам итү кебек тоела» [13: 5]. Татар прозасы тармаклана, төрле алымнарга байый. Бу, беренче чиратта, совет чынбарлыгын сурәтләүдә чагыла.

Язучылар моңарчы гел уңай яктан гына сурәтләнеп килгән коммунист җитәкче образының гаепләрен дә күрсәтә башлыйлар. Бу юлны Ә. Еники «Саз чәчәге» (1955) повесте белән башлап җибәрә.

Райкомда икенче секретарь булып эшләүче Шакир Мостафин, хатыны белән кызы юл һәлакәтендә вафат булгач, Наҗия исемле кызга өйләнә. Яшь хатын белән яши башлагач, Мостафин халык мәнфәгатьләрен кайгыртудан читләшеп, «шәхси милек колына» әверелә. Повестьта бу җитәкченең принципиальлеген акрынлап югалта баруы һәм эчке уйланулары аша бирелә. Хезмәт кешесенә тиешле товарны үзләштереп, җитәкчеләрнең гади халык тормышыннан аерылуы алар арасында упкын барлыкка китерүче сәбәп буларак күрсәтелә.

Ә. Еники әлеге әсәрендә ике зур проблема күтәрә. Берсе аның, әйткәнебезчә, җитәкче геройны тискәре яктан тасвирлау һәм шуның аша партия әгъзалары эшчәнлеген шик астына алу булса, икенчесе – Наҗия белән бәйле. Автор әлеге образны ачуга шактый зур игътибар бирә. Шакир башта кызның яшьлегенә, чибәрлегенә гашыйк булса, тора-бара аның рухи яктан бик ярлы, буш кеше булуын аңлап ала. «Аңа гына сыенып, аны гына назлап тора торган чәчәктәй нәфис Наҗиясе белән ул кешеләр алдында горур һәм бәхетле булыр кебек, әмма шул ук вакытта берни белми, берни уйламый торган җилбәзәк хатын белән адәм көлкесенә калыр һәм тирән бәхетсезлеккә төшәр шикелле...» [10: 145]. Автор сазлыкта үсә торган ут чәчәген символик образ буларак куллана. Бер яктан, тышкы гүзәллек рухи байлык белән тулыланганда гына чын бәхет була, ди автор. Икенче яктан, кешеләрнең байлыкка омтылып, матди якны гына кайгыртып яшәве – җәмгыятьне сазлыкка китерәчәгенә ишарәли – һәр заман актуаль булган мәсьәлә турында уйланырга этәрә.

Шулай итеп, бу чорда «без – алар» конфликтының яңа моделе барлыкка килә: ул җәмгыятьтә совет үлчәмнәренә туры килми торган кешеләр булуын күрсәтә. Шуның белән коммунистлар партиясенең

дөреслеге шик астына алына. Моның өчен автор үз әсәренә системаның кешеләрне, җәмгыятьтәге хәлләренә карап, ике лагерьга бүлүен күрсәтүче берничә эпизодны (мәсәлән, шикәр комы вакыйгасы: аны билгеле бер категория кешеләр генә чиксез күләмдә куллана алу; шәхси йорт салу; сугыш ветераны тормышы күренешләре һ. б.) кертә. Хакимият һәм гади хезмәт ияләренең тормышын һәм көнкүрешен җентекләп тасвирлап, гомумиләштермичә генә автор мондый күренешнең сәбәпләре турында уйланырга этәрә.

Җепшеклек чоры татар прозасы турыдан-туры бәя бирүдән кача, бу исә автобиографик жанрның активлашуында чагыла. Бер яктан, татар прозаикларының XX гасырның төп вакыйгаларына: күмәкләштерү һәм индустрияләштерүгә, шәхес культына, Гражданнар сугышына һ. б. яңача бәя бирү, үз карашларын җиткерү теләге туа. 1920–1960 елларда язучылар илдәге иҗтимагый-сәяси хәлләргә бәйле үз башларыннан кичкәннәрне яза алмыйлар. Икенче яктан, автобиографик әсәр аерым бер кешенең тормыш юлы тарихын сөйләргә мөмкинлек бирә. «Чорның кырыс хакыйкатен эзләү барышында язучылар хыял белән тулыландырылган, баетылган шәхси биографияләренә мөрәҗәгать итәләр. Бу әсәрләр сугыштан соңгы прозаның мөһим казанышына әверелә» [4: 5].

Ф. Хөснинең «Минем тәрәзәләрем» (1962–1964) автобиографик повесте гадәти истәлекләрдән торган әсәр генә түгел. Ул, жанры таләп иткәнчә, авторның шәхси тормышыннан алып язылган һәм әдипнең гомер юлы, иҗади үсеш баскычлары турында тулы мәгълүмат та бирә, идея-эстетик кыйммәте белән дә игътибарга лаек. Язучы әдәби иҗат мәсьәләләрен үзенең шәхси кичерешләре аша сурәтли, яшь каләмдәшләренә, үз тәҗрибәсеннән чыгып, сабак алырдай киңәшләрен бирә.

Авылда туып үскән гади крестьян баласының олы тормышка аяк басуы, борын канатып егылулар, ачы алданулар аша бернигә карамый һәрвакыт алга, яхшылыкка омтылуы, кеше булып калуның авыр да, җаваплы да булуы җанлы сурәт, шаян юморга бай сыгылмалы тел белән язылган. Лирик герой тормыш маягы итеп туган халкына хезмәт итүне куя. Шәхси бәхеткә ирешү белән бергә милләт мәнфәгатьләрен кайгыртып яшәүнең мәгънәле һәм сәгадәтле гомер булуын үз тормышы мисалында күрсәтә. Әдәбият галимнәре Н.Л. Лейдерман һәм М.Н. Липовецкий, 1960–1970 еллар рус әдәбиятының үзенчәлеген билгеләп, болай дип язалар: «Прорыв из-под глыб тоталитарного сознания, который начался в годы “оттепели”, расшатывание жесткой парадигмы соцреализма и поиски иных путей художественного освоения действительности уже не удалось остановить в годы политического застоя и идеологических “заморозков”» [16: 13].

Г. Бәшировның «Туган ягым – яшел бишек» (1968) повесте – татар халкының инкыйлабка кадәрге яшәү рәвешен якты буяулар белән сурәтләгән тәүге әсәрләрдән. Повесть тарихи-биографик жанрда иҗат ителгән. Бер яктан, ул автобиографик: язучы балачак һәм үсмерлек

чоры хатирәләрен яза, икенче яктан, истәлекләргә бәйләп, XX йөз башы татар авылын тарихи-панорам планда сурәтли. «Туган ягым – яшел бишек» повесте – Г. Бәшировның илдәге җепшеклек чорыннан файдаланып язылган әсәре. Бу елларда милли тарихка игътибар нык арта һәм моңарчы тыелып килгән тарихи вакыйгаларны яңгыратырга мөмкинлек туа.

1960 еллар – җәмгыятьтә дингә бәйле каршылыклы дәвер. Бер яктан, совет дәүләте динне тыя һәм аңа каршы кырыс сәясәт алып бара. Бу чорда дингә каршы көрәш алымы да үзгәрә. 1920–1930 елларда ул агитацион рухта булса, 1950–1960 елларда атеизмны пропагандалау фәнни аңлату эшләре белән алып барыла башлый. Шул максаттан күпсанлы мәкаләләр, хезмәтләр чыга. (Мисал өчен, П.Ф. Колоницкий [15], З.С. Әхмәров [1], Р.Г. Балтанов [2] хезмәтләре шундыйлардан.) Татар язучыларыннан Г. Гобәйнең «Коръән серләре» дә шул елларда языла. Икенче яктан, сугыш елларында йомшаруны тоеп алган язучылар үзләренең әсәрләрендә дини мотивларны, образларны кыюрак куллана, дини-рухи кыйммәтләргә ешрак мөрәҗәгать итә башлыйлар.

«Туган ягым – яшел бишек» әсәрен шартлы рәвештә сөйләнгән вакыйгаларга һәм хикәяләү стиленә нисбәтле өчкә бүлеп карарга мөмкин. Повестьның баштагы бүлекләрендә геройның гамьсез балачак чоры сурәтләнә: колын туу вакыйгасы, сабантуй, печән һәм урак өсте, аулак өй, каз өмәсе, туй йолалары этнографик яссылыкта бирелә. Язучы халыкның дөньяга карашын, яшәү рәвешен, тормыш шартларын, рухи дөньясын ача. Балаларның кышын чана шуу, карга боткасы пешерү, җәен корылык көннәрендә су сибешү, ат саклау вакыйгаларын автор яратып һәм сагынып искә төшерә. Халык яшәешенең авыр яклары турында язганда сагыш сизелсә дә, монда тормышны сөюче шук герой алга чыга һәм хикәяләүдә юмор өстенлек итә. Алга таба Гомәрнең шәкертлек чоры: абыстайда уку; мәдрәсә тормышы: төп геройның белем алырга омтылуы; халыкның дин өчен көрәше, бердәмлеге сурәтләнә. Соңгы бүлекләрдә Гомәрнең тегүчелектә йөрүе, этисезлек чоры башлана, халыкның социаль тормышына, сәяси якка игътибар ителә.

Повестьның яңалыгы шунда: Г. Бәширов моңарчы әдәбиятта «искелек калдыгы» итеп каралган йолаларны матурлык һәм яктылык чыганагы буларак күрсәтә. Бу авторның дини гореф-гадәтләргә, дин әһелләренә, мәдрәсәгә мөнәсәбәтендә дә чагыла. Билгеле, 60 нчы елларда боларны турыдан-туры язу мөмкин булмый, шулай да сурәтләнгән вакыйгалардан, аерым детальләрдән язучының дингә хөрмәт белән караганын аңларга була.

Совет җәмгыятенең беренче яртысында дин белән бергә дин әһелләрен дә тискәре образ буларак күрсәтеп киленде. Алар лагереның икенче ягында – халыкны изүчеләр рәтендә каралып, явызлык яки көлке объекты буларак сурәтләнде. Г. Бәшировның дин әһелләренә мөнәсәбәтен берьяклы гына дип әйтеп булмый. Соцреализм шартларында әдип персонажларга аларның социаль чыгышларына бәйле

мөнәсәбәттә булырга мәҗбүр: байларга, алпавытларга Гомәрнең антипатиясе сизелеп тора. Әмма дин әһелләренә автор уңай мөнәсәбәттә. Бу геройларның тышкы кыяфәтен сурәтләгәндә дә күренә. Беренче хәреф таныткан Фатыйма абыстай малайга «озын буйлы, озынча ак йөзле, төз гәүдәле, чибәр генә апай» [3: 95] булып күренә. Каенсар мулласы турында да автор «Ыспай гәүдәле, күркәм кыяфәтле яшь кенә кеше иде. Аның атнасына ике-өч тапкыр кереп чыгуы да безнең өчен зур яңалык була. Һич югында, аның матур, ак чыраена, сабак тыңлаганда калын кара кашларының гел селкенеп торуына карап утыруы да күңелгә хуш килә иде» [3: 122], дип яза.

Гомәр үз авылы мәдрәсәсендә Зәбихулла хәлфәдән белем ала. Язучы мәдрәсә тормышын, анда белем алуларны тасвирлаганда әлеге мөгаллим образына шактый туктала. Аның турында: «ул авылда, мулла белән мөәззиннән кала, иң әдәпле, иң гыйлем, иң үрнәк кеше», дип язуы белән автор, совет чоры прозасында беренчеләрдән булып, татар халкында дин әһелләренең зыялы, затлы һәм авторитет булуын күрсәтә. Шулай ук дин сабагы бирүчеләрнең балаларны бушка яисә бик аз керемгә укытуын берничә урында геройларыннан әйттерә. Әсәрдә инкыйлабка кадәр татар кешесе өчен исламның яшәү рәвеше булуы ассызыклана. Мөхәммәтҗан солдат белән Бәшир ага әңгәмәләрен автор махсус совет укучысына дин турындагы фикерләрен җиткерү өчен бирә.

«Тулысы белән XX йөз башы татар авылын сурәтләүгә багышланган әсәр инкыйлабка кадәрге тормыштагы матурлыкны, белемгә һәм яктылыкка омтылышны, кешеләр арасындагы җылы мөнәсәбәтләрне, йола-гадәтләр күркәмлеген һәм ямен тергезә. Әйтерсең лә ул 1917 елга кадәрге татар тормышының идеология тәкрарлап торганча наданлык һәм караңгылык оясы булмаганлыгын татар укучысына аңлату, җиткерү, күрсәтү максаты белән язылган» [13: 226].

60 нчы елларда милли үзаң уяну халыкта үзенең үткәне белән кызыксыну тудыра. Борынгы чорлар тарихын әдәби яктыртуга беренчеләрдән Н. Фәттах алына. Аның «Этил суы ака торур» романында (1969) X йөз башы – Идел буе Бөек Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итү чоры вакыйгалары сурәтләнә. 80 нче еллар уртасыннан тарихны яңача аңлау һәм яңача өйрәнү башлангач, Казан ханлыгы чорын яктырту мөмкинлеге туа һәм язучылар әлеге катлаулы һәм фаҗигалы тарих сәхифиләренә дә мөрәҗәгать итә башлыйлар. Тарихи әсәрләрдә халыкның милли үзенчәлекләре, бигрәк тә милли холкы ачыла. Әлеге мәсьәләне фәнни өйрәнүче А.М. Сафина «Национальный характер в исторических произведениях раскрывается посредством создания такого типа, который вбирает в себя представления о глубинных традициях народа, весь духовно-нравственный опыт предшествующих поколений и эволюцию его под влиянием времени» [20: 11] дип яза.

Тарихчы Ә.Г. Галләмова, Сталин вафатыннан соңгы чорны бәяләп, болай ди: «Несмотря на репрессии и идеологические императивы,

установить тотальный контроль над умами и действиями людей властям не удалось. Ужесточение идеологии оказывало иногда на общество прямо противоположное значение – усиливало творческую энергию. При всем казавшемся незыбленном господстве официальной идеологии в обществе сохранился и зрел гражданский активизм, пусть и в ограниченном зародышевом состоянии» [7: 1].

Турыдан-туры булмаса да, яшь язучылар иҗатында коммунистик идеологияне текст асты мәгънәләре, киная һәм эзоп теле белән инкяр итүләр башлана. Р. Батулланың үз чорында күпләрне аптыраштa калдырган «Монар» (Мираж) (1966) хикәясендә Исәнгол һәм Рәүф исемле ике ир, юлны бутап, машиналары белән чүлгә кереп адаша. Язучы оста психологик детальләр белән чүлдә калган кешенең чарасыз халәтен тасвирлап бирә. Сусызлык, билгесезлек, котылгысыз үлем куркынычы геройларны чыгырыннан чыгара. Тора-бара Исәнголның күзенә ерак түгел генә шәһәр күренә башлый. Рәүф юлдашын акылга китерергә омтыла, тик аны ишетергә дә теләмәгән Исәнгол шул билгесезлеккә таба юл тота. Моның мираж гына булуын белсә дә, Рәүф иптәше артыннан китәргә мәҗбүр була. Әсәр тулысынча яшерен эчтәлеккә корылган, аны хикәя-метафора дип атарга мөмкин. Берәүләрнең коммунизм идеясенә ихластан ышануын, алдануын, икенчеләрнең хакыйкатьне аңлый торып та, башкаларга иярергә мәҗбүр булуын яшь Батулла «коммунизм чәчәк аткан» дәвердә үк шартлы рәвештә әйтеп бирә.

1950 еллар башында Татарстанның көньяк-көнчыгыш районнарында нефть табыла, һәм ике дистә ел эчендә республика Советлар союзында иң күп нефть чыгаручы өлкәгә әверелә. ГЭС, заводлар, гигант төзелешләр Татарстанның индустриаль йөзен нык үзгәртә. Рәсми әдәбиятта производство өлкәсен яктырткан әсәрләр күпләп языла: әдәбиятка яңа тема, яңа геройлар килә. Аларда энтузиазм, яңа тормыш төзүче яшь геройның якты хыяллары өстенлек итә. Шул ук вакытта кайбер каләм ияләре мәсьәләнең башка якларына да игътибар итәләр. Нефтьчеләрнең җиргә саксыз мөнәсәбәте, ундырышлы кара туфракны эштән чыгарып, бозып бетерүләре аларны битараф калдырмый.

Башта мондый экологик проблемалар очерк формасында яктыртылса, аннан М. Хәбибуллинның «Икмәк кадере» (1972), Р. Төхфәтуллинның «Чатта тукталу» (1978) кебек повестьларында күтәрелә. Язучылар публицистик кискенлектән акрынлап әдәбилеккә күчеп, игенче психологиясен ачуга әһәмият бирәләр. Шулай итеп, татар әдәбиятында кеше һәм табигать мөнәсәбәтен проблема рәвешендә яктырту нефтьчеләр темасы белән башлана.

1960 еллар әдәбиятында реакцион агым – авыл прозасы – социалистик реализмның каршысы буларак формалаша һәм шул чорның төп юнәлешләренең берсе булып китә. Л.Б. Четырова һәм А.С. Сахаров соцреализм әсәрләрендәге маркерларны билгелиләр һәм аларның авыл прозасында капма-каршысы булуын күрсәтәләр. Алар – үзәк

герой итеп яшь кеше алыну, вакыйгаларның төзелештә яки сугыш кырында баруы, героика, антогонизм һәм бәхетле финал. Авыл прозасында боларның киресе – өлкән яшьтәге геройлар, прогресс нәтиҗәсендә туган җирне югалту, героика булмау күзәтелә. «Трагизм, лишенный национальной героики, с которым в произведениях описываются последствия политических событий или, что еще более характерно, вмешательства метрополии в деревенскую жизнь, например, коллективизации, позволяет нам говорить о колониальной ране советского крестьянства – неспособности адаптироваться в чуждом им модерном советском мире» [27: 105].

1980 елларга кадәр татар әдәбиятында социалистик реализм һәм авыл реализмы янәшә яши (И. Гази, Р. Төхфәтуллин, Б. Камалов иҗатлары). Бүгенгенең матурлыгын җырлаучы соцреализм язучыларыннан аермалы буларак, крестьян прозасы вәкилләре матурлыкны үткәннән эзлиләр, аны гореф-гадәтләрдә, җир кешесенең күңел байлыгында күрәләр, авылны традицион әхлакый кыйммәтләрне саклаучы урын буларак күрсәтәләр. 1960–1970 елларда авыл прозасы сугыштан соңгы авыр тормыш, колхоз җитәкчелеге белән бәйле вакыйгалар, геройның тормыш турындагы уйланулары белән характерланса, 1970–1980 елларда авыл һәм шәһәр тормышын бер-берсенә каршы кую, кешене табигать баласы буларак күрсәтү, фәлсәфи һәм психологик башлангычларның көчәюе күзәтелә. Авыл прозасы әдәбиятта миллилеккә басым ясый. Әсәрләрдә тамыр, нәсел, нигез, хәтер, шәҗәрә образмотивлары еш кулланыла. Язучыларны буыннар алмашы өзелү, эчкечелек, туган телнең кулланылу даирәсе елдан-ел тарая бару борчый.

Буыннар алмашы мәсьәләсе – әдәбиятның борынгы чорларыннан ук һәрвакыт төп проблемаларның берсе. XX йөзнең 70 нче елларында әлеге проблема яңа эчтәлек ала: рус авыл прозасы вәкилләре В.Г. Распутин, В.П. Астафьев, Ф.А. Абрамов һ. б. иҗатында ул әхлак, гореф-гадәтләрне, табигатьне саклау мәсьәләләре белән бергә күтәрелә. Татар әдәбиятына исә әлеге тема иртәрәк, 60 нчы еллар уртасында килеп керә һәм рус әдәбияты белән чагыштырганда аермасы да бар. Татар әдәбиятында буыннар бәйләнеше милли идеяне җиткерү максатында бирелә. Буыннар өзелү – милләт бетүгә китерүче сәбәп итеп күрсәтелә һәм бу тел, әхлак, хәтер, туган җир, нигез, катнаш никах мәсьәләләре белән бәйләп карала.

Ә. Еники әлеге мәсьәләне беренчеләрдән булып күтәрә. Аның «Әйтелмәгән васыять» (1965) повестендагы Акъәби тормышта үзенең аналык вазифасын рухи-мәдәни кыйммәтләрне саклауда күрүче героиня буларак сурәтләнә. Әмма, кызганычка каршы, мирас итеп тапшырылырга тиешле кыйммәтләрне ул тапшыра алмый кала: яңа чор кешеләре булып формалашкан үз балалары, оныклары аны аңламый. Заман үзгәреше китереп чыгарган әлеге буыннар алмашындагы өзеклек авторның милләт киләчәге өчен сызлануы булып аңлашыла [8: 625].

Р. Батулланың «Юл буенда зәңгәр чәчәк» повесте (1985) – совет чорына караган соңгы әсәрләрдән. Повестьтагы вакыйгалар Бөек

Ватан сугышыннан алып, 80 нче елларга кадәр вакытны иңли һәм татар авылы иҗтимагый, фәлсәфи, психологик һәм әхлакый яссылыкта сурәтләнә. Әсәрнең исеменә чыгарылган зәңгәр чәчәк образы матурлык символы буларак килә һәм геройларның матурлыкка (гаделлеккә, шәфкатьлелеккә, гамьлелеккә) мөнәсәбәте аларның яшәү принципларын билгеләүче факторга әверелә.

Әсәрдә вакыйгалар төп герой Ярмөхәммәткә бәйле алып барыла. Сугыш һәм кызыл террор китергән фаҗигалар әхлакый планда карала. Әсәрдә авыр сугыш еллары китергән яраларның гомерләр үтү белән генә төзәлмәве, киресенчә, торган саен аларның милләт нигезен какшата гына баруы күрсәтелә. Батулла төп геройның хәтерендә чордашларының язмышларын берәм-берәм бәян итә һәм кеше – нигез – авыл – милләт чылбыры аша аерым кеше бәхетсезлеген милли фаҗига дәрәҗәсенә үстерә.

«Юл буенда зәңгәр чәчәк» – Батулланың милли әдәбиятыбыздагы крестьян реализмы агымында язылган иң матур һәм тәэсирле әсәрләреннән. Авыл тормышын чынбарлыкка охшатып, ваклыкларда сурәтләү, авылны рухи байлык сакланып калган урын дәрәҗәсенә күтәрү әсәрдә шушы тормышны идеаллаштырып, романтик әсәрләргә хас алымнар белән башкарыла [12: 95]. Шул рәвешле, повесть татар әдәбиятын тамырдан үзгәрткән, социалистик реализм юнәлешенең асылына тәэсир ясаган авыл прозасының иң матур үрнәкләреннән дип бәяләнә.

Авыл прозасы совет чоры әдәбиятын төгәлләүче күренеш буларак чыгыш ясый. Рус әдәбиятында аның чикләре 1960–1980 еллар белән билгеләнсә, татар әдәбиятында алга таба XX йөз ахырында үсеш алачак милли яңарыш әдәбиятының чишмә башы булып исәпләнә. «Совет чорында татар әдипләре басым астында иҗат итсәләр дә, рөхсәт ителгән темаларда зур уңышларга ирештеләр, сәнгатьчә камиллек җәһәтеннән дөнья әдәбияты дәрәҗәсендә иҗат иттеләр. Чөнки алар моңарчы ирешелгән казанышларга таяндылар, югары художестволылыкка омтылдылар» [24: 287].

Шулай итеп, 1960–1985 еллар татар совет әдәбиятының тематик һәм жанр төрлелеге, шулай ук әдипләрнең милли мәнфәгатьләрне яклауда кыюлыгы белән билгеләнгән чор була. «Җепшеклек» үткәннәргә яңача, хәзергегә тәнкыйди карарга һәм онытылган исемнәрне һәм әсәрләрне әдәби әйләнешкә кайтарырга юл ача. Автобиографик жанр язучыларга XX гасырның фаҗигалы вакыйгалары турында шәхси тәҗрибә призмасы аша җиткерергә мөмкинлек бирә. Г. Бәшировның «Туган ягым – яшел бишек» повесте көнкүреш һәм йолалар картинасын тудырып кына калмый, исламны татар халкы тормышының аерылгысыз бер өлеше итеп тә күз алдына китерә.

Идел буе Бөек Болгар дәүләтен сурәтләгән тарихи романнардан алып коммунистик идеологияне тәнкыйтьләүче хикәя-метафораларга һәм экологик проблемаларны күтәрүче әсәрләргә кадәр бу чор татар әдәбияты темаларның киң спектрын колачлый, милли кыйммәтләргә,

тарихи хәтергә һәм буыннар алмашыну проблемасына игътибарын юнәлткән авыл прозасы аерым урын алып тора.

Күзәтүләр күрсәткәнчә, совет чорында татар прозасы XX гасыр башы әдәби традицияләрен яңартып, тематик һәм сәнгати яктан тотрыклы үсә. Бу үсеш тулаем алганда ике юнәлеш буенча бара. Берсе сыйнфыйлык һәм партиялелек принципларына нигезләнә һәм рәсми идеологиягә буйсына, икенчесе – бу чикләрдән чыгарга һәм гомумкешелек идеалын гәүдәләндерүгә омтыла. Әмма язучылар ике юнәлештә дә соцреализмнан чыгу юлларын эзлиләр, милли үзенчәлекләрне, мәдәниятне, тарихи хәтерне сакларга омтылалар.

Татар совет әдәбиятының революциядән соңгы беренче эзләнүләрдән алып «җепшеклек» чорында чәчәк атуына кадәрге юлы авыр һәм каршылыклы була. Миллилекне чагылдыруга омтылу, гуманистик идеаллар һәм сәнгать хакыйкатен эзләү идеологик кысалар, цензура һәм басым астында бара. Шуңа да карамастан, әдәбият милли үзенчәлеген саклап кала һәм татар мәдәниятен үстерүгә зур өлеш кертә.

Шулай итеп, татар совет әдәбияты халыкның катлаулы һәм күпкырлы тарихын чагылдырган бай мирас калдыра. Ул, чорның сәнгати чагылышы гына булып калмыйча, милли үзаң формалашуның, мәдәни традицияләрне кайтаруның, саклауның һәм аларны киләчәк буыннарга тапшыруның куәтле факторы да була.

**Әдәбият**

1. *Ахмеров З.С.* Воспитывать атеистов. Из опыта работы школ Татарской АССР. М., 1962.

2. *Балтанов Р.Г.* Утверждение коммунистической нравственности и борьба с пережитками морали ислама: автореф. дис. ... канд. филос. наук. Казань, 1963.

3. *Бәширов Г.* Туган ягым – яшел бишек: повесть // Бәширов Г. Әсәрләр: 4 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. 2 т. 452 б.

4. *Гайнуллина Г.Р.* XX гасырның 60–70 нче елларында татар автобиографик прозасы үсеше. Казан: Ихлас., 2012. 107 б.

5. *Галимуллин Ф.Г.* Реализммы, романтизммы? // Табигыйлеккә хилафлык. Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. 321 б.

6. *Галимуллин Ф.Г.* Татарская литература: взгляд сквозь столетия. Казань: Школа, 2016. 295 с.

7. *Галлямова А.Г.* Татарская АССР в период постсталинизма (1945–1985 гг.). Казань: Татар. кн. изд-во, 2015. 455 с.

8. *Ганиева А.Ф.* Архетип матери-хранительницы национальной идентичности в татарской прозе // Вестник Удмуртского университета. Серия История и филология. Т. 32. 2022. № 3. С. 623–629.

9. *Гыйззәтуллин Н.* Хикәяләр остасы // Социалистик Татарстан. 1967. 30 апр.

10. *Еники Ә.* Саз чәчәге // Ә. Еники. Әсәрләр: 5 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. 2 т.: повестьлар. 447 б.

11. *Җәләй Л.* Киң җәймәдәге таплар // Совет әдәбияты. 1934. № 9. Б. 81–89.

12. *Заһидуллина Д.Ф.* Караш җитмәсне колачлаган әдип // Чын мирас. 2013. 3 март. Б. 91–98.

13. *Заһидуллина Д.Ф.* 1960–1980 еллар татар әдәбияты: яңарыш мәйданнары һәм авангард эзләнүләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. 383 б.

14. *Ибраһимов Г.* Кызыл чәчәкләр // Әсәрләр: 15 томда. 3 т.: хикәя, повестьлар, роман, драма. Казан: Татар. кит. нәшр., 2018. 422 б.

15. *Колоницкий П.Ф.* Мораль коммунистическая и мораль религиозная. М., 1952.

16. *Лейдерман Н.Л., Липовецкий М.Н.* Современная русская литература: 1950–1990-е гг.; пособие для студ. высш. учеб. заведений: в 2 т. Т. 2: 1968–1990. М.: Изд. центр «Академия», 2003. 688 с.

17. *Максуд М.* Тагын «Командир» романы турында // Совет әдәбияты. 1935. № 7. Б. 85–89.

18. Матур әдәбият фронтында кулак идеологиясенә каршы // Атака. 1931. № 5–6. Б. 6.

19. *Надыршина Л.Р.* Поэма в татарской литературе XX века. Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова. 2022. 352 с.

20. *Сафина А.М.* Национальный характер в татарской исторической прозе (вторая половина XX века): автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 2010. С. 11.

21. *Скороспелова Е.Б.* Русская проза XX века: от А. Белого («Петербург») до Б. Пастернака («Доктор Живаго»). М.: ТЕИС, 2003. 420 с.

22. Фатих Хөсни иптәшнең белдерүе // Атака. 1931. № 7. Б. 42–43.

23. *Халит Г.* Романтизмны һәм реализмны яклап // Казан утлары. 1967. № 8. Б. 105–114.

24. *Хатипов Ф.М.* Әдәби әсәрнең эстетик энергиясе. Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. 287 б.

25. *Хафизов С.* Гаугалы роман // Социалистик Татарстан. 1991. 2 август.

26. *Хөсни Ф.* Йөзек кашы // Хөсни Ф. Бер яшьлектә, бер картлыкта: повестьлар, хикәяләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. Б. 8–52.

27. *Четырова Л.Б., Сахаров А.С.* «Деревенская проза» в контексте столкновения традиционной русской культуры и советской модерности // Семиотические исследования. 2023. Т. 3. № 2. С. 99–106.

**_Ганиева Айгөл Фирдинат кызы,_**
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

**_Ганиева Айгуль Фирдинатовна,_**
*кандидат филологических наук, старший научный сотрудник отдела литературоведения Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*

*aygulgani@mail.ru*